МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.03.2024 Казан ш № 196

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булып торган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм белдерүләрнең алыну тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы указы белән расланган Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәнең 16 пунктындагы «б» пунктчасы, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау турында» 2023 елның 28 августындагы 701 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү

һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасы нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булып торган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм белдерүләрнең алыну тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2024 елның
21 мартындагы 196 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булып торган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм белдерүләрнең алыну тәртибе

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булып торган мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрләр алыну тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында (алга таба, тиешенчә – Министрлык, җаваплы зат) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка түбәндәгеләрнең килү процедурасын регламентлый:

Министрлыкның «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм үзләренең хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга бурычлы булган Министрлыкның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2018 елның 16 июлендәге 560 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм үзләренең хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга бурычлы булган Министрлыкның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегендәге дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинның коммерциячел яки коммерциясез оешмада вазыйфаи биләүгә граждани-хокукый шартнамә шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруга ризалык бирү турында мөрәҗәгате, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи

(хезмәт) бурычларына караган булса, дәүләт хезмәтеннән куылган көннән соң ике ел узганчы;

Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәреннән (алга таба – дәүләт хезмәткәре) объектив сәбәпләр аркасында хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмавы турында гариза;

территориясендәге чит ил банкларында счетлары (кертемнәре) булган, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләре сакланган һәм (яисә) чит ил финанс кораллары булган чит ил дәүләтендә компетентлы органнар тарафыннан әлеге чит ил дәүләте законнары нигезендә салынган арестка, эш итүне тыюга бәйле рәвештә яки үз ихтыярына яки хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка төрле шартлар аркасында дәүләт хезмәткәреннән – «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмавы турында гариза.

Дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турындагы белдерүне алу һәм карау тәртибе Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибен раслау турында» 2016 елның 16 мартындагы 77 номерлы боерыгы белән җайга салына.

2. Гражданинның мөрәҗәгатьләре һәм дәүләт хезмәткәренең гаризалары (алга таба – мөрәҗәгать (гариза)) министрга (аның вазыйфаларын башкаручыга) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының эшчәнлек алып бару бүлеге аша әлеге Тәртипкә 1, 2 һәм 3 нче кушымталар нигезендә язма рәвештә тапшырыла.

3. Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (аның вазыйфаларын башкаручы) мөрәҗәгать (гариза) килгән көннән алып өч эш көне эчендә аны коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка алдан карау өчен җибәрә.

4. Мөрәҗәгатьне (гаризаны) алганнан соң җиде эш көне эчендә алдан карау нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгатьтә (гаризада) комиссия утырышын үткәрү өчен нигезләр булган мәгълүмат булган очракта, җаваплы зат тарафыннан мөрәҗәгать (гариза) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

5. Комиссия мөрәҗәгатьне (гаризаны), аңлатмаларны һәм башка материалларны Министрлыкның «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау турында» 2023 елның 28 августындагы 701 номерлы боерыгы белән расланган Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә нигезендә карап тикшерә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булып торган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм белдерүләрнең алыну тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына

_________________________________________

_________________________________________

(Ф.И.А. – соңгысы булган очракта), били торган вазыйфа һәм структур бүлекчә, яшәү урыны адресы, телефон номеры)

Объектив сәбәпләр аркасында хатын (ир) һәм балигъләк яшенә җитмәгән балаларның керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмавы турында гариза

Түбәндәгеләргә карата керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру мөмкинлегенә ия булмавым турында хәбәр итәм

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

(Хатын (ир) һәм (яки) балигълык яшенә җитмәгән балаларның фамилиясе, исеме, ата исеме, туган көне)

чөнки_______________________________________________________________________

(Комиссия мәгълүматны тапшырмау объектив һәм ихтирамлы характерда дигән нәтиҗә ясый алсын өчен кирәкле барлык сәбәпләр һәм шартлар күрсәтелә)

Гаризага түбәндәге өстәмә материалларны (булган очракта) терким:

_____________________________________________________________________________

(өстәмә материаллар күрсәтелә)

Күрсәтелгән мәгълүматларны тапшыруда граждан хезмәткәре күргән чаралар:

_____________________________________________________________________________

Әлеге мөрәҗәгатьне караганда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим/ниятләмим (кирәклесе астына сызарга).

«____» ________ 20__ ел      _____________      ________________________

(имза)      (тулы имза)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булып торган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм белдерүләрнең алыну тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына

______________________________

________________________________________
(Ф.И.А. соңгысы – булган очракта), били торган вазыйфа һәм структур бүлекчә,

________________________________________
яшәгән урын адресы, телефон номеры)

Гариза

Территориясендәге чит ил банкларында счетлары (кертемнәре) булган, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләре сакланган һәм (яисә) чит ил финанс кораллары булган чит ил дәүләтендә компетентлы органнар тарафыннан әлеге чит ил дәүләте законнары нигезендә салынган арестка, эш итүне тыюга бәйле рәвештә яки үз ихтыярына яки хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка төрле шартлар аркасында дәүләт хезмәткәреннән «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлегенә ия булмавым турында хәбәр итәм, чөнки

________________________________________________________________________
(Комиссия федераль закон таләпләрен үтәмәүнең сәбәбе объектив һәм хөрмәтле характерда диган нәтиҗә ясый алсын өчен кирәкле барлык сәбәпләр һәм шартлар күрсәтелә)

Гаризага түбәндәге өстәмә материалларны (булган очракта) терким:

________________________________________________________________________
(өстәмә материаллар күрсәтелә)

Кабул ителгән чаралар:

______________________________________________________________________________

Әлеге мөрәҗәгатьне караганда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим/ниятләмим (кирәклесе астына сызарга).

«____» ________ 20__ ел ____________ ______________________

(имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булып торган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм белдерүләрнең алыну тәртибенә 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына

_______________________________________

_______________________________________

(Фамилия, исем, ата исеме
(соңгысы – булган очракта),
били торган вазыйфа һәм структур

_______________________________________

бүлекчә, яшәгән урын

_______________________________________

адресы, телефон номеры)

Коммерциячел яки коммерциясез оешмада вазыйфа биләүгә яисә коммерциячел яки коммерциясез оешмада хезмәт яки гражданлык-хокук килешүе шартларында эш башкаруга ризалык бирү турында мөрәҗәгать

Мин,

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________,

(Ф.И.А. тулысынча, туган көн, яшәү урыны адресы)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын билим

_______________________________________________________________________,

(структур бүлекчәне күрсәтеп, вазыйфа атамасы)

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы нигезендә __________________________ вазыйфасын биләүгә ризалык бирүегез турында үтенәм

_______________________________________________________________________

(гражданин биләргә ниятләгән вазыйфаның исеме)

(кая) ________________________________________________________

(коммерциячел оешма яки коммерциясез оешма атамасы)

Яки гражданлык-хокукый килешү шартларында эшләрне башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) гражданин башкарачак эш төрләре, хезмәтнең исеме) ______________________________________________________________________

(шартнамә төре, коммерциячел оешма яки коммерциясез оешма атамасы)

________________________________________________________________

(башка түләүле эшне башкару вакыты)

Шартнамә буенча эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) түләү суммасы: ______________________________________

Минем вазыйфаи бурычларым (мин башкарачак эш) түбәндәгеләрдән гыйбарәт булачак:

______________________________________________________________________

(хезмәт яки гражданлык-хокукый килешү төзелгән очракта, вазыйфаи бурычларның кыскача тасвирламасы, башкарылган эшнең характеры )

Коммерцияле яки коммерциясез оешма өчен дәүләт идарәсе функцияләре: ______________________________________________________________________

Әлеге мөрәҗәгатьне караганда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим/ниятләмим (кирәклесе астына сызарга).

«____» ________ 20__ ел ____________ ______________________

(имза) (тулы имза)